РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального района

423303, Азнакаевский район, с. Агерзе,
ул.Г.Ахметовой, д.14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

423303, Азнакай районы, Әгерҗе авылы,
Г.Ахметова урамы, 14а
тел.8(855-92)44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

от «20» октября 2025 г. — №1

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Әгерҗе торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Агерҗе авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Әгерҗе торак пунктында Әгерҗе авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 31 октябрендә 17 сәгать 30 минутка билгеләргә.
2. Билгеләү:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Әгерҗе торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты - 2025 елның 31 октябре 17.30 сәгатьтән 18.30 сәгатькә кадәр;

- гражданнар җыенын уздыру урыны – Әгерҗе авылы, Г. Әхмәтова ур., 14А йорт Әгерҗе авылы мәдәният йорты залы;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 20 октябреннән дә соңга калмыйча гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын тәэмин итәргә: Әгерҗе авылы, Г. Әхмәтова ур., 14А йорт;

- Әгерҗе торак пунктында сайлау хокукына ия халык исемлекләрен төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Әгерҗе торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Әгерҗе торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1,2,3 төркем инвалидлардан, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы гражданнардан тыш, 2026 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? түбәндәге эшләрне башкару

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Молодежная урамында вак таш сатып алу, төяү, ташу, салу);

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Әгерҗе авылы, Г. Әхмәтова ур., 14А йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә;

- Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan. ru.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә

Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге
Башлыгы А.Г.Мирзагитова